ИҢ ЯХШЫСЫ – БЕЗДӘ

Татарстанда «Агроволга – 2022» халыкара агросәнәгать күргәзмәсе узды

> 2

КЫР ЧӘЧӘКЛӘРЕ

Кәмәртдиновлар гаилә сукмагын инәгә-инә куеп 51 ел бергә атлый

> 3

АЛАНДА – «АЛМАШ»

Теләче районында авыл турында сериал төшерәләр

> 3

ИСӘНМЕСЕЗ! АВАН-И!

«Ватаным Татарстан» газетасының махсус проекты

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 97 (28870) | Шимбә | 9 июль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ИҢ ЗУР БӘЙРӘМ

Бүген барча мөселманнар изге бәйрәмебез – Корбан гаетен билгеләп үтә. Шимбәгә каршы төндә мәчетләребездә бәйрәм вәгазе сөйләнде. Иртәнге дүрт тулганда гает намазы укылды. Бу көнне һәр мөселман, дөнья эшләрен читкә куеп, вакытны гыйбадәт, туганнарны зиярәт кылу, бер-берeңне котлау, изге теләкләр теләү кебек савaплы гамәлләр белән уздыра.

Гөлүсә Закирова

Дөньяви җәмгыятьтә яшәсәк тә, рухи тормышыбыз – дини йолаларыбыз, гореф-гадәтләребез турында да онытмыйбыз. Аллаһы Тәгалә кушканнарны үтәп, ул әманәт итеп калдырган кыйммәтләрне кадерләп яшәргә тырышабыз, шөкер. Нурлат районының Түбән Нурлат микрорайонында яшәүче Бикташевлар Корбан гаетен шатланып көтеп ала. Быел алар яңа йорт җиткезгән, гаеткә дип яңа мунчаны да өлгерткәннәр.

– Корбан гаете – безнең – мөселманнарның иң зур бәйрәме. Аны ел саен үткәрәбез. Балаларыбызга да дини бәйрәмнәребезнең асылын аңлатабыз, гореф-гадәтләребезне өйрәтәбез. Корбан бәйрәмендә ел саен корбан чалабыз. Бу көнне ирем гает намазына бара. Алдан гает мунчасы кереп, икенче көнне иртүк таба исе чыгарып, мул табын әзерләп, Корбан гаетен шулай бәйрәмчә каршылап, бәйрәмчә үткәрәбез, – ди хуҗабикә Фирүзә Бикташева.

Дини җырлар башкаручы Ильяс Халиков гаиләсендә дә Корбан гаете һәр ел саен мөселманнарны берләштерә торган зур бәйрәмгә әверелә. «Ишегалдында коймак, пылау пешә. Вәгазь дә сөйләп алабыз. Шул рәвешле корбан чалу үзенә күрә бер тәрбияви чарага әверелә», – ди ул. Күпләргә мәгънәле җырлары аша таныш Ильяс Лаеш районында урнашкан хуҗалыгында корбанга сарыклар үрчетә. Аларны алдан да, көнендә дә сатып алырга мөмкин. Кирәк икән, бер төркем сугымчы сарыкларны шунда ук чалып, эшкәртеп тә бирә. Корбан итен мохтаҗларга илтеп, таратып бирү мөмкинлеге дә каралган.

Изге бәйрәмнәребез якынлашкан көннәрдә күңел дигәнең аеруча нечкәрә. Начар гамәлләр, начар уйлардан арынасы, чистарынасы, догада булып, изге теләкләр генә телисе килә. Күңелне генә түгел, әйләнә-тирәсен дә чистартырга, пакьләргә тырыша мөселман кешесе. Бәйрәм алдыннан йорт-җирне юып чыгару, чистарту, бәйрәм көнне сый-нигъмәтләр белән табын кору – елның-елында башкарыла торган гамәлләр.

Иман йортларыбызга да игътибар арта ул көннәрдә. Әле берничә көн элек кенә Яшел Үзән районының Олы Шырдан авылы халкы мәчеттә өмә оештырган. «Корбан гаете алдыннан хатын-кызлар белән барыбыз бергә җыелып, авылыбызның мәчетен юып, чистартып чыгардык. Бу чара бездә ел саен үтә, иман йортыбызны карап торабыз, шөкер. Быелгы өмәдә катнашкан барлык хатын-кызларга рәхмәт яусын», – ди шушы авылда яшәүче Наҗия Хәсәнова. Корбан гаете алдыннан Кама Тамагы районының Балтач авылы халкы да иман йортын пакьләндергән.

Корбан гаете көнне башкалада, республикабыз районнарында төрле бәйрәм чаралары уза. Соңгы елларда авылларда да Корбан гаетен зурлап, чын бәйрәмчә уздыру матур гадәткә әверелеп бара. Балтач районының Арбор авылында да быел Корбан гаетен әнә шулай зурлап уздырачаклар. Изге бәйрәм көнне туган авылында шундый зур бәйрәм оештыру хезмәттәшебез Зөлфия Хәлиуллинаның күптәнге хыялы була.

– Корбан, Ураза гаетләрен һәркем өендә зурлап үткәрсә дә, бәйрәмне шулай бөтен авыл халкы бергә зурлап беренче тапкыр гына үткәрүебез. Күптәнге хыялым бу. Безнең авылда, балаларны җыйнап, Тукай урамы бәйрәме дигән чара үткәрелә иде. Шушы бәйрәмне гает көнне үткәрсәң яхшы булыр иде, дип уйлый идем. Нишләптер һич җыенып бетә алмадык. Аннары авылның уңганнарын, оста куллы кешеләрен дә бер мәйданга җыясы килде. Аларның кайсы аш-суга оста, кайсы бәйли, кайсы тегә. Әмма безнең якта халык әйбер сатарга күнекмәгән. Аларны да үз әйберләрен танытырга, сатарга өйрәтәсе килә. Менә шушы ике теләкне чынга ашырып, быел үзебезнең авылда Корбан гаете бәйрәмен зурлап үткәрергә булдык, – ди ул.

Зөлфия ханымның тәкъдимен Арбор халкы да, колхоз җитәкчесе дә куәтләп ала, иганәчеләр дә табыла. Бәйрәм көнне авылда корбан итеннән пылау пешәчәк, саф һавада тәмле коймак белән чәй эчәргә дә мөмкин булачак. Балалар өчен аерым мәйданчык булып, биредә махсус аниматорлар эшләячәк. Моннан тыш бәйрәм мәйданчыгында эбру (суда рәсем ясау) буенча мастер-класс та үтәчәк. Арбор осталары үзләре җитештергән эшләнмә, әйберләрне дә сатачак.

– Бүген кешегә аралашу җитми. Сабантуйларда да ихласлык аз. Элек кеше бозау, каз суйса да, төрле өмәләрдә дә, печән җыйганда да күрешә иде. Очрашу өчен сәбәпләр күп иде. Бүген кеше белән кешенең аралашуы юк. Шуңа күрә мондый бәйрәмнәр кирәк, тансык. Хәдисләребез дә кунакка йөрешергә, бүләкләр бирешергә, дуслар, туганнар белән аралашырга өнди. Гает көнне һәр кешенең күңелендә яхшылыкка, яктылыкка, изгелеккә урын күбрәк була. Корбан гаете бәйрәменә дә кеше башка төрле кәеф белән килә. Кешенең бирегә чиста күңел белән килүе аның кыйммәтен тагын да арттыра. Шуңа күрә икенче бер югарылыкта үтәр дип өметләнәм, – ди Зөлфия Хәлиуллина.

КОРБАН ГАЕТЕ МӨБАРӘК БУЛСЫН!



Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм МИҢНЕХАНОВның Корбан бәйрәме уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле татарстанлылар!

Кадерле ватандашлар!

Сезне изге Корбан гаете – Гайд әл-Әдха белән чын йөрәктән тәбрик итәм!

Дөнья мөселманнары бу ямьле бәйрәм көннәрендә олы мәрхәмәт буларак кешеләргә гөнаһлардан арыну һәм диндарлык юлларын күрсәткән Ярлыкаучы Аллаһка сыгынып, ихластан дога кыла. Изге Мәккәгә күңелен һәм уйларын юнәлткән, хаҗ сәфәренә чыккан миллионлаган мөэмин алдында хәзер дә, бик борынгы заманнарда кебек үк, кешеләрнең җанын иман нуры белән яктырта, сабыр тынычлык иңдерә һәм киләчәккә якты өмет уята торган бөек хакыйкать ачыла.

Корбан ул – Аллаһның әмеренә буйсыну, без аның нигъмәтләренә шөкер итәбез. Коръән Кәрим Раббының ризалыгына ирешергә, ата-аналарыбызга, газиз туганнарга, ятимнәргә, мохтаҗларга, әйләнә-тирәдәге һәркемгә карата мәрхәмәтле булырга өйрәтә. Хәзерге четерекле заманда бу сыйфатлар кешелек өчен аеруча мөһим һәм тансык.

Үзенең бик борынгы шәфкатьлелек һәм хәйрия традицияләре белән дан тоткан Корбан гаете – республикабызда иң зур һәм иң мөкатдәс бәйрәмнәрнең берсе. Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын бөтен Россия күләмендә уздыру белән бәйле рәвештә ул быел аеруча зур тантана төсен ала.

Күбебез бу юбилей уңаеннан мәйданга килгән тарихи вакыйгаларның шаһиты булдык, аларда катнаштык. 922 елда борынгы бабаларыбызның дәүләт дәрәҗәсендә ислам динен кабул итүе күпчелек очракта Көнбатыш һәм Көнчыгыш традицияләре бергә үрелгән үзенчәлекле Россия цивилизациясе барлыкка килүнең, безнең гаять киң мөселман дөньясының аерылгысыз бер өлешен тәшкил итүебезнең алшарты булды.

Мәрхәмәт иясе Аллаһның чиксез рәхмәте өчен аңа мәдхияләребезне күндерү белән беррәттән, динебез таралган башлангыч чорда күп хезмәт куйган, гасырлар дәвамында халыкны Раббыбыз күрсәткән хак юлдан тайпылдырмыйча алып барган шәхесләрнең олуг гамәлләрен бүген дә зур хөрмәт хисе белән искә алабыз. Корбан бәйрәме рухи офыкларыбызны киңәйтсен, иҗади хезмәттә булу һәм Ватаныбызны яклау өчен безгә бәрәкәтле көч бирсен!

Сезгә чын йөрәктән тынычлык, иминлек, бәхет телим. Барлык хәерле эшләребездә Аллаһ безне ярдәменнән ташламасын! Бәйрәм мөбарәк булсын!

170 машина бурыч түләүгә киткән

Ел башыннан Татарстан суд приставлары салым түләмәүчеләрнең 1764 мөлкәтенә (барлыгы 496 миллион сумлык) арест салган. Шул исәптән 273е – күчемсез милек (263 миллион сумлык), 603е – машина (215 миллион сумлык).

Бурыч түләнмәгән очракта, суд приставы арест салынган мөлкәтне сатуга озата. Аны сатудан кергән акча әҗәтне каплауга тотыла. Узган елда бурычлыларның барлыгы 1 миллиард 300 миллион сумлык мөлкәте сатуга тапшырылган. Шуның бер өлеше сатылып, 204 миллион 630 мең сум акча кергән. Бурычын түләмәүчеләрнең сатылган мөлкәте арасында – фатир, торак булмаган бина, җир кишәрлеге һәм 170 машина.

Яхшы хәбәр

Җиңүчеләр билгеле

Казандагы Җәмигъ мәчетенең нинди эскиз буенча төзеләчәге билгеле. Мәчетнең эскиз проектына игълан ителгән халыкара бәйгенең җиңүчеләре дип Казан архитекторы Айвар Саттаров белән Ginzburg Architects архитектур бюросы табылды.

Җиңүчеләрнең исемен кичә Казан Ратушасында игълан иттеләр. Чарада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

«Җәмигъ мәчетенә нигез салыну – Идел Болгарында ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулу уңаеннан булган вакыйгалар арасында иң әһәмиятлесе. Бәйгедә катнашучыларның барысына да зур рәхмәт әйтәсем килә. Һәр проект уникаль. Барлык эшләрне дә яраттым. Аларның барысы да җиңүгә лаек. Сез тудырган образларны башка объектларыбызда гәүдәләндерергә тырышачакбыз», – диде Татарстан Президенты тантанада.

Хәтерләсәгез, 20 май көнне Җәмигъ мәчетенә нигез ташы салынды. Ул төзеләчәк эскизга бәйгене исә 1 апрельдә үк игълан иткәннәр иде. Аны «Игелек – Доброта» җәмгыятенең рухи-әхлакый үсешенә ярдәм итү республика фонды оештырды. Бәйгедә җиңү яулаган проект авторына – 2,5 миллион сум, икенче урынга – 1 миллион сум, өченчегә 500 мең сум акча вәгъдә ителде. Бүген инде Җәмигъ мәчетенең тышкы кыяфәте нинди булачагы да билгеле булды.

Бәйгедә барлыгы 40 архитектор катнашты. Алар 3 ай буе 8,2 га мәйданда 10 мең кешегә исәпләнгән, машина кую урыннары булган яңа иман йорты проектын эшләде. Мәчет манарасының биеклеге, мәйданы, фасадлары, стилен дә архитекторлар үзләре хәл итәргә тиеш иде. Россия, Мисыр, Төркия, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Казахстан һәм Үзбәкстаннан килгән 18 катнашучы финалга үтте.

«Реальное время» / Максим Платонов

КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр институты директоры, жюри әгъзасы Рамил Хәйретдинов сүзләренә караганда, финалга узган эшләрне тикшергәндә белгечләр проектка салынган төп фикергә игътибар иткән, аларның чор рухын ни дәрәҗәдә чагылдыруын бәяләгән.

Билгеле булганча, Казанда Җәмигъ мәчетен төзү Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулу уңаеннан 2022 елда уздырыла торган төп чараларның федераль планына кертелгән. Аны быелның көзендә төзи башларга җыеналар.

Сүзгә-сүз

council.gov.ru

Елена ПИСАРЕВА, Федерация Советының Фән, мәгариф һәм мәдәният комитеты әгъзасы:

Хәзер мәктәптә озайтылган көн төркемнәрен ачканда әти-әниләрнең фикерен исәпкә алу мәҗбүри түгел. Төбәкләргә өстәмә финанслау хокукы биреләчәк һәм бу – әти-әниләр азрак түләячәк дигән сүз. Продленкада укучылар өй эшләрен эшләячәк, түгәрәкләрдә өстәмә белем алачак, күргәзмәләргә һәм концертларга бара алачак.

(Федерация Советының пленар утырышыннан)

ТАТАРСТАНДА – ГАИЛӘ КОРУЧЫЛАР

«Татарстанстат» мәгълүматларына караганда, 2021 елда 24649 пар гаилә корган. Узган ел хатын-кызлар арасында 20–24 яшьтә кияүгә чыгучылар күбрәк булса, ир-атлар 25–29 яшьтә ешрак өйләнгән икән.



Җәйдән әзерләнәләр

Республикада җылылык бирү сезонына 1349 котельный (42,6%) әзерләп куелган инде. Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары Илдус Насыйров әйтүенчә, 1255 уку йорты (планның 38 проценты), 891 сәламәтлек саклау оешмасы (44%), 827 мәдәният объекты (42,2%) кышкы салкыннарга тулысынча әзер. Күп катлы торак йортларга килгәндә, 5553е (45,6 проценты) тиешле әзерлеккә куелган.

Май башында Казан мэры Илсур Метшин җылылык бирүгә әзерләнү барышында якынча 2 мең чакрым озынлыктагы тышкы торбаүткәргечләрне, 9 мең чакрымга сузылган эчке торбаүткәргечләрне юдыру, гидроопрессовка ясауның күздә тотылуын белдергән иде.

Сүз уңаеннан, республикада яшәүчеләрнең яртысы чамасы (44 проценты) узган кышта йортларны җылытудан канәгать калган. Сораштыруда катнашучыларның (барлыгы 700 кеше) 30 проценты – «канәгатьләнерлек», 24 проценты «канәгатьләнмәслек» дип җавап биргән.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ



Наил ШӘРИФУЛЛИН

Пандемия: хушлашабызмы?

Бүтән битлек кимәячәкбез. Төрле дистантлар, локдауннар, ара саклау, теңкәгә тигән QR-кодлар, ПЦР-тестлар да булмаячак. Роспотребнадзор, инде атна, ун көнләп булыр, ковидка кагылышлы бөтен чикләүләрне гамәлдән чыгарып куйды. Моны илнең, планетаның ике елдан артык барыбызны тинтерәткән зәхмәттән котылуы, ким дигәндә шуның башы дип аңларгамы? Әллә инде чокырны сикереп чыкмас борын ук «һоп» диюме бу?

Беренчесе булуын телисе, шуңа бик ышанасы килә, әлбәттә. Чөнки апрель, майлардан бирле, Роспотребнадзор әле берни дә дәшмәгәндә дә, ярыйсы тугарылган идек инде. Шыгрым тулы автобусларда да, сәүдә үзәкләрендә дә битлек киеп йөргәннәр яздан ук азая барды. Табиблардан башкалар гомерендә дә киеп карамаган ул авыз-борын каплавычыннан тәмам туйган, гаҗизләнгән халык чирнең җиңел кичерелә башлавын, үлем-китемнең кимүен сизүгә «азынмый» кая барсын?! Күпләр тарихтан да хәбәрдар бит әле: һәр пандемиянең дә башы булган кебек, азагы да булмый калмаган. Бер гасыр элек ялрап, шактый мул «уңыш» җыйган «испанка» да 2–3 ел үтүгә тынычланган, бераздан гел булмаган кебек юкка да чыккан.

Бүген пандемия белән хушлашып маташканда, аңа кагылышлы аерым сораулар куяр, җавап эзләр, кайбер нәтиҗәләр ясар вакыт кебек. Вирус лабораториядән качканмы, әллә үзеннән-үзе ялралганмы, дигәндә җавап бирү, әлбәттә, авыр. Белгечләр, махсус хезмәтләр кайчан да булса мәсьәләнең төбенә төшеп, ни дә булса тәгаен әйтә дә алыр. Тагын да шул «испан гриппы»н искә төшергәндә, анысын беркем дә әвәләп утырмаган бит. Ул вакытта вирусология белән микробиология ялралгы хәлендә генә булган. Әмма чир ялралган. Шунлыктан, ковид дигәндә, Кытайны, Уханьны, андагы лабораторияләр, галимнәрне гаепләү дөрес, нигезләнгән гамәл түгел, диясе килә. Табигатьтә һәр тере җан иясе мутация кичерә. Кеше, хайваннар, үсемлекләрдән аермалы буларак, микродөнья – вируслар дөньясында, вакыт агышы гел башка булу сәбәпле, үзгәрешләр күпкә тизрәк бара. Таҗлы вирус, аның явыз мутациясе дә, көтмәгәндә, уйламаганда, руслар әйтмешли, «как черт из табакерки» килеп чыкты да, бөтен Җир шарында мәшһәр оештырып, ике ел ярым буе безне җан, корбаннар сорап бимазалады. Һәм дә шул ике ел ярым эчендә, үзгәрүен, эволюциясен туктатмыйча, ниһаять, патогенлыгы, ягъни кешене аяктан егу сәләте шактый түбән булган версиясен – «омикрон»ны тудырды. Шулай ук без артык көтмәгәндә.

Вирус, үзгәрә килеп, «омикрон»га һәм «омикрон-стелс»ка җитүгә, күпләрнең котын очырып, йогышлыдан үтә дә йогышлыга әверелгән иде. Аның әшәкелеген – кешенең үпкәсен, кан тамырларын, башка органнарны эштән чыгару үзлеген югалтуын, ихтимал, вирусологлардан башкалар көтмәгәндер дә. «Омикрон» – бүген һәммәбез дә диярлек йоктырган, үзендә йөрткән, кемнәрдер сизелер-сизелмәс кенә авырып та алган, тик авыр ялкынсыну, фаталь нәтиҗәләргә китермәгән яисә сирәк китергән штамм. Табиблар хастаханәгә эләгүчеләрнең 98–99 проценты инфаркт, инсульт, бүтән шундый катлаулы чирләр белән авырып китеп, организм зәгыйфьләнгәч кенә шул штаммны эләктерүен, шул очракта гына чирнең авыр нәтиҗәләргә китерүен билгели. Ул үзлеге буенча вирус хәзер грипика якынайды. Ковид, бер академик билгеләгәнчә, инде безләрдән беркая да китмәячәк, янәшә яшәячәк бишенче таҗлы вирус икән. Борыннарыбызны юешләткән, карык-корык ютәлләткән һәм бер атна дигәндә иммунитетыбыз арт сабагын укытып куып җибәргән ОРЗ, ОРВИдан аның төп аермасы шунда: ул алар кебек сезонлы түгел, шунлыктан җәен дә, кышын да чирләтәчәк, ди галимнәр.

Килешегез, ковидка, пандемиягә кагылышлы без узган ел гына ишеткән кайбер куркыныч фаразлардан, «Чир ясалма, ул елдан-ел явызрак була барачак, җирдәге халык санын яртылаш киметмичә туктамаячак», – дигән сүзләрдән соң алда әйтелгәннәр – үзенә күрә бер яхшы сюрприз. Өметләнсәк тә, әле бер ел элек кенә пандемиянең 2022 елның җәендә ныклап чигенәсен без белми идек. Чөнки SARS-CoV-2 дигән зәхмәт агрессив һәм йогышлы фазага кергән иде. Британ штаммы, Бразилия, Көньяк Африка вариантлары, Һиндстанда ялралганы һ.б. «Дельта» дигәне хәтта ки яшьләргә ябышты. Һәм менә, ни гаҗәп, «омикрон» исемле мәрхәмәтлесе безне коткарырга алынды...

Ә вакцинация? Котылуыбызда ул нинди роль уйнады? Бу сораугa да дөрес җавапны, ихтимал, белгечләр бирер. Безгә аның объектив булуын гына теләргә кала. Вакциналар кеше гомерен, сәламәтлеген саклауда үз өлешен керткәннәрдер. Бәлки әле вирус эволюциясен дә тизләткәннәрдер. Тик барысы да түгел. Анысы тәгаен, дип әйтә алам. Бу юлларны язучы, кайбер сәбәпләр аркасында, вакцинаның «Спутник V» түгел, ә «ЭпиВакКорона» дигәнен ясаткан иде. Ясатып, ике ай вакыт үтәр-үтмәстән нәкъ шул вакцинаны җитештерүдән туктадылар һәм рәсми рәвештә аның файдасызлыгын таныдылар. Бу ни дигән сүз? Тулы институт, олы коллектив айлар буе ясаган, сынаган, ниндидер хикмәт белән сертификация үткән, инде дистә миллион кешегә кадалган вакцина өч тиенлек тә булмаган дигән сүзме? Ничек шулай була ала? Бу бит «ашыгып ашка пешү» – кабалану аркасында туган ялгышлык кына түгел. Миллионнарның организмына керәсе препарат ашыккан очракта да үз билгеләнешенә тулысы белән туры килергә тиеш. Медицина, Роспотребнадзор чиновниклары моның өчен нинди дә булса җаваплылыкка тартылганмы? Ул хакта сүз ишетелмәде. Ә вакцина файдасыз гына түгел, зарарлы да булган булса? Әлбәттә, андый очракта да дәшмәячәкләр. «ЭпиВакКорона» алган башкалар ничектер, салкын тиеп елына бер тапкырдан артык авырмаучы фәкыйрегез вакцина кадатканнан соң инде өч тапкыр җиңелчә авырырга өлгерде. Әлбәттә, биредә башка сәбәпләр дә булырга мөмкин, тик факттан качып та булмый. Ә таҗлы вирус белән урын өстендә ятмыйча гына авырган, канында антитәнчекләр эритроцитлар санынча ук булмаса да, чабышып-куышып йөргән кешегә вакцина кадауны кем кагыйдә иткән? Бу сораугa да җавап юк...

Бу юлларны язган мәлдә ковидка кагылышлы яңа хәбәр килеп ирешә. ВОЗ җитәкчелеге COVID-19ның аерым илләрдә яңадан баш күтәрүен, соңгы ике атнада чирләүчеләр санының яңадан артып китүен белдерде. Оптимизм белән яшәсәк тә, вирус «бүген бар, иртәгә – юк» схемасы буенча бездән китмәячәк. Ихтимал, ел дәвамында, бәлки әле киләсе елда да аның яңа, зәгыйфьрәк дулкыннары кузгалып алыр. Әмма ни генә булмасын, 2020–2021 еллардагы үтә дә начар вазгыять кабатланмас дип ышаныйк.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

ИҢ ЯХШЫСЫ – БЕЗДӘ

tatarstan.ru

Иң матур сыер, иң җитез трактор, иң кәттә техника һәм иң уңдырышлы культура. Татарстанда «Агроволга – 2022» халыкара агросәнәгать күргәзмәсендә боларның барысын да күрергә мөмкин иде.

Өч көн барган чарада Россиянең 42 төбәгеннән, шулай ук Төркиядән, Белоруссиядән, Көньяк Кореядан, Австралиядән һәм Нидерландтан 415 компания катнашты. Алар авыл хуҗалыгы техникасы, үсемлекчелек, терлекчелек, цифрлаштыру, авыл хуҗалыгы продукциясен саклау, эшкәртү һәм төрү буенча яңа эшләнмәләрен тәкъдим итте. 48 гектар мәйданда тәҗрибәкүрсәтү кырлары оештырылган иде.

Күргәзмәнең беренче көннәрендә иң матур сыерны ачыкласалар, механизаторлар «Трактор-шоу» төбәк ярышларында трактор йөртү осталыкларын күрсәтте. Биредә шулай ук һөнәри осталык һәм иң яхшы ветеринар-ортопед конкурсы да узды. Мәсәлән, иң матур сыер өчен голштин токымлы 40 тана көч сынашты. Алар барысы да продуктлылыгы буенча дөнья һәм Европа дәрәҗәсенә ирешкән сөтлебикәләр иде. Җиңүчене сайлаганда исә аның күпме сөт бирүе, гәүдәсе, тыгызлыгы, аяклары, җилене һәм хәтта атлап йөрешенә кадәр бәяләнде. Ә чемпион исеме Балтач районының «Кызыл Юл» кооперативы сыерына бирелде. Аның беренче тапкыр бозаулагач сөт бирү күләме 12,8 мең килограммны тәшкил итә икән. Икенче һәм өченче урыннарны Кукмара районының «Восток» һәм Мамадыш районының «Продовольственная программа» җәмгыяте сыерлары алды. Моннан тыш, таналар иң нечкә бил, иң нәзакәтле йөреш, иң тигез арка линиясе, иң яхшы темперамент, тамашачылар мәхәббәтен яулау һәм башка шундый кызыклы номинацияләр буенча көрәште.

Кичә исә әлеге күргәзмәне Россиянең авыл хуҗалыгы министры Дмитрий Патрушев, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Брянск өлкәсе губернаторы Александр Богомаз һәм башка җитәкчеләр карады. Аңа кадәр Рөстәм Миңнеханов кулланучылар кооперациясе оешмаларына автолавка һәм икмәк ташу өчен 16 автомобиль тапшырды. Ул авыл җирендә яшәүчеләр өчен уңайлы шартлар тудыруның өстенлекләрнең берсе булуын билгеләп узды.

– Авыл территорияләрендә барлык кирәкле дәүләт хезмәте күрсәтүләр булырга тиеш. Моңа халыкны күчмә сәүдә белән тәэмин итү дә керә, – диде ул.

Татарстан Президенты билгеләп үткәнчә, бу эштә кулланучылар кооперациясе оешмалары зур роль уйный, алар турыдан-туры авыл кешеләре белән эшли.

– Без бу системаны саклап калдык. Бүген күчмә сәүдә итүне тәэмин итүче автомашиналар паркы 121 автомобильдән тора. Алар барысы да график буенча эшли, төрле ярдәм формалары гамәлгә ашырыла. Бу эш бик мөһим, – дип билгеләп узды Рөстәм Миңнеханов.

Шуннан соң кунаклар белән бергәләп күргәзмә мәйданын карап, аны югары бәяләделәр. Дмитрий Патрушев Татарстанның күп юнәлешләрдә алдынгы урыннар биләвен билгеләп узды.

– Мондый зур чара икенче ел гына узса да, күргәзмә үзен яхшы яктан күрсәтте. Мәйданнарда агросәнәгать комплексындагы иң югары технологияләр тәкъдим ителгән. Ул файдалы эшлекле элемтәләр булдырырга ярдәм итәр дип уйлыйм. Россия агросәнәгате үсә. Татарстан күп юнәлешләрдә югары позицияләрдә тора. Аерым алганда, сез коры һәм эшкәртелгән сөт җитештерү буенча алда барасыз. Һәм көнбагыш мае җитештерүдә беренче унлыкка керәсез. Моннан тыш, авыл хуҗалыгы машина төзелешен үстерер өчен яхшы базагыз бар, – диде ул.

Министр тиздән авыл хуҗалыгы өчен мөһим чор – урып-җыю сезоны башлануына да басым ясады. Игенчеләргә уңышлар теләде һәм министрлыкның алга таба ярдәм итәчәген ышандырды.

Рөстәм Миңнеханов исә республиканың барлык программаларда да катнашуын әйтте һәм рәхмәтен белдерде.

– Безгә бик күп кунаклар килде, үз продукцияләрен тәкъдим итте. Алар безне нәтиҗәле партнерлар буларак күрә, – диде ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Рөстәм Миңнеханов махсус хәрби операциядә катнашкан Росгвардия хезмәткәрләре белән очрашты.

Росгвардиячеләрне туганнары, якыннары, ветераннар һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары вәкилләре каршы алды. «Сез хәрби бурычыгызны намус белән башкардыгыз һәм үзегездә булган иң яхшы сыйфатлар – батырлык, чыдамлык, Ватанга булган мәхәббәтегезне күрсәттегез», – диде Президент, алдагы хезмәтләрендә уңышлар теләп.

Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, Ватанга һәм халыкка хезмәт итү юлын сайлаучылар, иминлек хакына тормышларын да кызганмыйча, чын каһарманлык күрсәтә. «Тарихыбыз йөкләгән җаваплылыкның ни дәрәҗәдә югары булуын һәркайсыбыз аңлый дип уйлыйм. Без һичшиксез җиңүгә ирешәчәкбез!» – диде ул.

Очрашу вакытында Рөстәм Миңнеханов Росгвардиянең Татарстан буенча идарәсе башлыгы, полиция генерал-майоры Рөстәм Гомәров белән Татарстан Республикасының дәүләт һәм ведомство бүләкләрен тапшырды.

Яшәеш

Һәр балага наз кирәк

Республикада яшәүче күпбалалы гаиләләр, тәрбиягә сабый алучылар ничек яши? Икесе ике төргә керсәләр дә, аларны күп итеп бала үстерү берләштерә. Ә хокуклары бертигез түгел.

Кичә Дәүләт Советындагы хатын-кыз депутатларның «Мәрхәмәт» оешмасы республика районнарында урнашкан бүлекчәләре җитәкчеләрен җыеп, әнә шул хакта сөйләште. Борчыган сораулар да юк түгел. Депутатларның максаты – тәрбиягә күп бала алган гаиләләрнең статусын үзгәртү. Аларны да күпбалалы гаилә дип атамакчылар.

– Күпбалалы гаиләләр төрле хокукларга ия. Ә менә ятимнәрне үз канаты астына алучылар бу җәһәттән читтә кала. Беләсезме, хәтта безнең кебекләр, бала алгач, аны бакчага чиратка да куя алмый. Ә тапкан ана, сабые тугач та, баласына бакча буласын белеп яши, – ди Әлфия Самсонова. – Мин былтыр ике кыз баланы тәрбиягә алдым. Аларның берсенә – 6, икенчесенә – 9 яшь. Кечкенәсен бакчага урнаштырганда, бик күп каршылыклар белән очраштым. Кая гына шалтыратмадым, әмма бернигә ирешеп булмады. Аптырагач, Казан мэрына хат яздым. Бары шуннан соң гына нидер кузгалды. Тик әле дә баламa бакча эләкмәде. Без 1 сентябрьдә бакчага барачакбыз.

Әлфия Самсонова кызының бакча тәрбиясе алмыйча мәктәпкә китүен теләми. Ятимнәр йортында яшәп, ул болай да күп нәрсәдән мәхрүм булган дип саный. Шуңа да шакымаган ишеге калмый.

– Бөтен кеше дә мин түгел. Кемдер, безгә чират юк икән дип, баласы белән өйдә утырырга мәҗбүр. Шуңа күрә бала алып үстерүчеләр дә сабыен бакчага урнаштыруда кыенлык кичермәсен иде, – ди ул.

Шулай ук ятимнәргә үз назын биргән Рима Вәлиева да күп кенә күңелсез хәлләргә юлыккан. Ул үзләрен күпбалалы әти-әни дип исәпләп, таныклык бирүләрен сорый.

– Җәйге чорда балалар белән матур җирләргә ял итәргә барасы килә. Тик күп кенә урыннарда, әйтик, зоопаркта үзләре табып өч һәм аннан күбрәк бала үстерүчеләргә ташлама бирәләр, ә безгә юк. Кай җиребез ким соң? – ди ул.

Баксаң, Рима Вәлиева кебекләр, үзләренең күп бала үстергәнен раслау өчен, һәркайсының документын күрсәтергә мәҗбүр икән.

Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе Светлана Захарова сүзләренчә, күп бала үстерүчеләргә йә бер төрле ташламаны, йә икенчесен сайларга кирәк булачак. Чөнки бала алып үстерүчеләр ятимнәргә фатир алырга хокуклы, күпбалалы гаиләләрнең үз ташламалары бар.

– Икесен дә бергә бутарга ярамый. Без хәзер ятимнәрне тораксыз калдыра күрмик. Кайбер мәсьәләләрне сөйләшеп тә хәл итеп булыр, кайберләренә закон рәвешендә ирешербез. Әмма безгә бу теманы бик ныклап өйрәнергә кирәк, – ди ул.

Дәүләт Думасы депутаты Татьяна Ларионова исә, Татарстан депутатларының теләк-тәкъдимнәрен, «Бердәм Россия»нең халык программаларын Дәүләт Думасы депутатлары да хуплап ала, ди.

– Төрле юнәлешләрдә эш бара. Безнең алда бер җирдә дә теркәлмәгән, тору урыны булмаган сабыйларның торак алу проблемасы тора иде. Ул да хәл ителде. Хәзер бала кайсы районда яши – торган урыны, теркәлгән җире булып шул санала. Татарстанда ятимнәрне фатир белән тәэмин итү буенча кыенлык юк. Без моның өчен Президентыбыз Рөстәм Миңнехановка рәхмәтле. Татарстан кебек, елына 600 баланы фатирлы итүче бер генә төбәк тә юк, – ди ул. – Гаилә хакында сөйләшкәндә, без гел әни һәм бала турында әйтә идек. Әтиләр читтә калып барды. Хәзер инде закон әтиләр хокукын да яклый. Күпбалалы гаиләләргә кагылышлы сораулар күп. Әле шушы көннәрдә Мәскәүгә федераль округлардан 10 гаилә килде. Алар арасында Татарстаннан Шуваловлар да бар иде. Алар авылда өченче баласын тапкан хатын-кызларга ярдәм күрсәтүне сорады.

«Мәрхәмәт» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе җитәкчесе Алсу Нәбиева сүзләренчә, алар авыл җирендә һәм бистәләрдә даими яшәүче хатын-кызларга өченче бала туганда түләүләрне федераль бюджет акчасы исәбеннән, яшен чикләмичә бирү мөмкинлеген карау тәкъдиме белән мөрәҗәгать итәләр. Әлеге тәкъдим Идел буе федераль округының барлык регионнары тарафыннан да хупланган. Димәк, эшләр җайга бара.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КЕРМИ ТОР УРМАННАРГА!

Кисәтү

Республикада янгын куркынычы зур булу сәбәпле, 8 июльдән урманнарга керү тыела. Бу чикләү Аксубай, Әлки, Әлмәт, Апас, Алабуга, Югары Ослан, Биектау, Кайбыч, Мамадыш, Минзәлә, Менделеевск, Түбән Кама, Нурлат, Тукай, Питрәч районындагы һәм Казан янындагы урманнарга кагыла. Ул 3 атна дәвам итәчәк.

Бу чорда урманнарда җиләк-җимеш җыярга, күңел ачарга, учак ягарга ярамый. Шулай ук машина белән дә керергә рөхсәт юк. Татарстан Урман хуҗалыгы министрлыгы хезмәткәрләре әнә шулай итеп табигатьне уттан сакламакчы була.

– Урманга керү юлларын шлагбаум белән ябачакбыз. Чикләүләр кертелгән чорда тәүлек әйләнәсендә безнең хезмәткәрләр кизү торачак. Көннәр бик эссе тора. Быел республикада 6 июльдән һава температурасы күтәрелде. Алдагы көннәрдә эссе һава сакланачак. Кызу көннәр 4 нче дәрәҗәдә янгын куркынычы тудыра, – ди Татарстан урман хуҗалыгы министры урынбасары Илгизәр Зарипов. – Татарстанда янгынга каршы махсус режим быелның 25 апрелендә бер кертелгән иде инде. Узган ел ул биш тапкыр кертелеп, чикләүләр 25 октябрьгә кадәр дәвам итте. Ул чакта без республика буенча янгынга каршы торуга әзерлек алып бардык. Һәр районда видеоэлемтә аша очрашулар уздырдык. Алар барысы да гадәттән тыш хәлләргә әзер икәнлеген әйтте. Хәзер безнең максат – урманнарны саклау.

Министр урынбасары сүзләренчә, янгыннарның 90 проценты кеше факторы аркасында килеп чыга. Шуңа да урманчылар халыкка сак булырга куша. Әйтик, узган ел Сарман районында көтүче йоклап китеп, тәмәке төпчеге үләнгә төшеп ут чыга. Берәүләр исә урман эчендә тимер-томыр кисә. Аларның очкыннары да янгынга сәбәп була. Министрлык ут-күз килеп чыкса, ярдәмгә әзер икәнен әйтсә дә, бу хәлләрне булдырмас өчен кулдан килгәнне эшлиләр. Татарстанда төрле типтагы 25 урман-янгын станциясе эшли. 14 урында янгынга каршы җиһазлар әзерләнеп куелган. Урманнарны 1 меңгә якын кеше саклый. Шулай ук космостан да күзәтәләр. Лаеш районында урнашкан диспетчерлык үзәгенә янгын турында хәбәрләр килеп тора икән. Кайчак ниндидер бина, күп вакытта коры үлән януын беренчеләрдән булып алар күрә. Тиз арада янгын чыккан урынны билгеләп, шул тирәдә урнашкан урманчылыкка хәбәр бирәләр икән.

Урманчылар халыкны да уяу булырга чакыра. Берәр урында үлән янганын күрсәләр, 8-800-100-94-00 телефонына хәбәр бирүләрен сорыйлар.

Илгизәр Зарипов, урманда гына түгел, аңа якын урыннарда да ут белән мавыкмаска куша.

– Әгәр янгын куркынычсызлыгы таләпләре бозыла икән, ял итүчеләрне штраф көтә, – ди ул.

САН

Чикләүләр вакытында урманга кергән кешеләргә 15 меңнән 30 мең сумга кадәр штраф каралган. Вазыйфаи затларга – 30 меңнән 50 мең сумга кадәр, юридик затларга 600 меңнән 1 миллион сум күләмендә акча түләргә туры киләчәк.

minleshoz.tatarstan.ru

«АВЫЛ ХАЛКЫ ӘРТИСТКӘ ӘЙЛӘНЕП БЕТТЕ»

«ТНВ» ТЕЛӘЧЕ РАЙОНЫНДА ЯҢА СЕРИАЛ ТӨШЕРӘ

Авыл фәлсәфәсен 20 сериялек сериалда ачып буламы? Юктыр, мөгаен. Әмма йөзгә, төскә үзгәргән заманча авыл турында сөйләргә, аны күрсәтергә кирәк. Шушы максатларны истә тотып, Теләче районында «Алмаш» дип исемләнгән татарча сериал төшерә башладылар. Кадрларга эләкмәсәк тә, төшерү мизгелләрен без дә күреп кайттык.

«Татар-информ» / Салават Камалетдинов

Бу эшне «Татарстан – Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау һәм үстерү мәсьәләләре буенча комиссия һәм «Татнефть» хәйрия фонды ярдәме белән гамәлгә куйган. Төшерүчеләр – «Ватан – XXI гасыр» кинокомпаниясе.

Эшне комиссия рәисе Марат Әхмәтовның хәер-фатихасы белән башладылар. «Узган ел без «Татарстан – Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе белән бергәләшеп «Бер-бер хәл» сериалын төшергән идек. Әлеге матур традицияне дәвам итәргә булдык. «Алмаш» та үз тамашачысын табар, телебезне саклап калу, үстерүгә үз өлешен кертә алыр дип уйлыйм», – диде ул.

«Татарстан – Яңа Гасыр» җитәкчесе Илшат Әминов сүзләренчә, тамашачы чит ил сериалларын карап туйды. «Халык үз тормышын күрсәтә торган, үзенә якын булган темаларга һәм үзебезнең артистлар төшкән фильмнар сорый. Әлеге эшне без шушы ихтыяҗны үтәр өчен башкарабыз. Темалар күп, туктамаска, тагын да кызыклырак сериаллар төшерергә кирәк», – диде ул.

Теләче районы башлыгы Нәҗип Хаҗипов сүзләренә караганда, авыл кешеләре чын әртисткә әйләнеп беткән. «Бу сериалны 40, 100 серияле итәрлегебез бар безнең. Районда, гомумән, республикада мондый фильмнар төшерер өчен мөмкинлекләр, матур урыннар да бик күп. «Алмаш»та өч авыл халкы катнаша, яртысыннан артыгы артист булып бетте инде», – диде ул.

Нәрсә турында?

Сериалның режиссеры – Алмаз Әкбәров әйтмешли, авыл турындагы күп кенә стереотипларны юкка чыгарырга кирәк. Сериалның максаты була бусы. Гади итеп кенә әйткәндә, заманча авыл тормышын күрсәтәчәкләр. «Саладагы тормыш, яшәеш шулкадәр үзгәргән. Авыл, диюгә, кайберәүләрнең күз алдына пычрак, заманадан артта калган күңелсез тормыш килеп баса. Бу фикерне юкка чыгарырга, авылда яшим дисәң, бөтен мөмкинлекләр булуын күрсәтергә телибез. Ни өчен нәкъ менә Теләче, диярләр. Монда рельефлар төрлелеге бар. Без бит кадрларның матур булуын да кайгыртабыз», – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

Сценарий авторы Альберт Шакиров та, режиссерның сүзләрен җөпләп һәм уены-чыны белән бергә, бер генә алабута тырпаеп торса да, кадр бозыла, ди. «Үрнәк татар авылы дигәндә авыл хуҗалыгы алга киткән төбәк килеп баса. Эшлим, яшим, дигән кешегә барлык мөмкинлекләр дә булган авыл. Ә бит авыл бүген дә пычрактан чыкмаган, артта калган булып күзаллана 1990 нчы еллардагы авыл образы. Ләкин ул үзгәрде, аның күрсәтер яклары, яшьләрне чакырып кайтарыр өчен җирлек бар», – диде ул.

Ямьле Алан

Сүз уңаеннан, «Бер-бер хәл» сериалына да сценарийны Альберт Шакиров язган иде. Сериалларның төшерү технологияләре шактый аерыла, ди ул. «Сериал саен камилләшәбез. Җитештерү процессында алга китеш сизелә. Иң мөһиме – туктамыйча төшерергә һәм тагын да камилләшергә кирәк».

Бу фикер белән актерлар буенча режиссер Радик Бариев та килеште. «Бу юлы җитешсезлекләрне шомартып, нәрсә җитмәгәнен тәгаенләп эшкә керештек. Миңа калса, сценарий бик кызыклы. Сериал үз тамашачысын һичшиксез табар дип уйлыйм. Ләкин бер мәсьәлә ачык кала бирә. Әгәр без серияләрне телевизордан күрсәтеп кенә калмыйча, махсус мәйданчыкка да урнаштырсак, сериалны караучыларны тагын да арттырып булыр иде. Бик күпкә», – диде ул.

Аннан төшерү процессы турында да сораштык. «Безне бик кайгырталар монда. Район башлыгы да күзәтеп кенә тора, кирәк нәрсәне шундук таба. Төп вакыйгаларны Алан авылында төшерәбез, авыл җирлеге башлыгы бөтенләй яныбыздан китми. Үз машинасына кадәр бирде», – диде Радик Бариев.

Үтереп мактады ул Алан авылы башлыгы Булат Хәсәновны. Табып, үзе белән сөйләшми булдыра алмадык. «Авылны төзегән вакытта староста таугa менеп баса да, йортларның, урамнарның тигезлеген, матурлыгын тикшереп тора. Шуңа да бик матур безнең авыл, төз, пөхтә. Яңа сериал да табигатьнең бөтен матурлыгын үзенә сыйдырган урында төшерелә. Табигатен генә түгел, матур кешеләрен дә күрсәтергә, тарихка кереп калырга тырышабыз. Балалар, оныклар белән карап, сокланып утырырлык булсын иде», – дип сөйләде ул безгә.

Бер Фәннүргә – ике роль

Режиссер Алмаз Әкбәровтан сериалның исеме турында сораштык. «Тормышта безгә төрле рольләр башкарырга туры килә. Кайчак алар безгә бөтенләй ят булырга мөмкин. «Алмаш» исә үзең булып яшәргә өнди. Бу исем сайлануның икенче сәбәбе исә ярылып ята. Бер-берсенә холыклары буенча аз гына да охшамаган игезәкләргә урыннарын алыштырырга туры килә. Шуннан башлана да инде маҗаралы хәлләр», – дип аңлатты ул.

Төп геройлар – Әмир һәм Сәмир исемле игезәкләрне Камал театры артисты Фәннүр Мөхәммәтҗанов башкара. «Икесе ике төрле кеше. Берсе – авыл зоотехнигы, икенчесе – шәһәр бизнесмены. Холыклары буенча охшамаганнар. Рольнең кызык ягы да, катлаулы ягы да шул», – ди ул.

Аннан тыш төп рольләрне Әсхәт Хисмәтов, Айгөл Шәкүрова, Фирая Әкбәрова, Искәндәр Хәйруллин, Радик Бариев һәм Татарстан театрларының башка артистлары башкара. Сериалны көз көне «ТНВ» телеканалыннан күрсәтергә ниятлиләр.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Үрнәк гаилә

Илфруз абый хатыны Альбирага һаман да кыр чәчәкләре җыеп бүләк итүдән туктамый. Әнә берсендә көтү каршылаганда, сыер артыннан чабып тирләп-пешеп беткән, тик хатынына дип өзгән чәчәкләрне ташлап калдырмаган. Ромашкалар, кыңгыраулар шиңгән саен яңасын өзеп алып кайтып тора икән. Буа районының Адав-Толымбай авылында яшәүче Кәмәртдиновлар гаилә сукмагын иңгә-иң куеп 51 ел бергә атлый...

Илдар Мөхәммәтҗанов

БҮЛӘККӘ – КЫР ЧӘЧӘКЛӘРЕ

Бирегә Әгерҗе якларыннан килен булып килә ул. Буа медицина көллиятенә укырга дип килгән кыз, әйтерсең, бу төбәккә үз язмышын корыр өчен ашкынган. Яңавыл мәктәбе директоры Нәби Әхмәтов аны: «Габдрахманова, 8 нче сыйныфны укып бетергәч, Арча көллиятенә укырга барасың да аннан безнең мәктәпкә башлангыч сыйныфларны укытырга кайтасың», – дип кисәткән. Ничек инде, ул бит укытучы түгел, табиб булырга хыяллана?.. Тик үпкәләтермен дип, күңелендәге теләген әйтергә кыймаган ул. Директор исә аның мәктәптә бары яхшы билгеләргә генә укуын, район, шулай ук «Яшь ленинчы» газетасы битләрендә мәктәп тормышы турында мәкаләләре басылуын күреп торган. Өстәвенә дружина советы председателе, комсомол секретаре да бит! Шуңа күрә булдыклы кызны үз мәктәбеннән читкә җибәрәсе килмәгәндер, күрәсең. Тик Альбира ничек итсә иткән, директор абыйсына: «Арчага барам», – дип Буага киткән. Ә бит ак халат киярге теләве дә юктан түгел. Әгәр аның туган авылы Бәзәкәдә фельдшер булса, ул башкача уйлар иде. 40 хуҗалыклы кечкенә авылда халык еш авырый, дәвалаучы кеше юк, ярдәм күрсәтүче аз. Нәкъ менә шул чакта шәфкать туташы булу теләге уяна анда. Гомерен авыруларны дәвалауга багышлавына бер дә үкенми. Күрше Ивашевка һәм Яңавылда алты ел фельдшер булып эшли. Аннан Адав-Толымбай авылындагы авыру балалар өчен интернат-мәктәптә медицина ярдәме күрсәтә. Тик уку йорты ябылгач, Альбира апа социаль хезмәткәр эшенә күчә. Ялгыз әбиләрне карау өчен дә йөрәкнең олысы кирәк бит.

...Ә мәктәп директоры кушканны үтәмәве гел күңелен тырнап торган. Буада шәфкать туташына укый башлагач, авылга кайткач, урамда очраткан ул мәктәп директорын. Үзен гаепле санаган кыз аны кочаклап алып: «Абый, гафу итегез берүк, мин сезне алдап киттем бит», – дигән. «Кем дә кем, тик, Габдрахманова, синнән моны көтмәгән идем», – дигән директор. Өстеннән тау төшкән кебек булган Альбираның. Ни генә дисәң дә, үз бәхетенә үзе киртә кормаган. Әгәр Буага ашкынмаган булса, Илфрузын да очратмаган булыр иде, бәлкем.

Беренче елны Буада бер апада яшәгән Альбира. Анда кәҗә савып, кабартма пешереп көне үткән. Болай булмый бит, укыйсы бар. Икенче елны иптәш кызлары белән булачак ире Илфрузның туганнары йортына күченгән. Менә шунда танышканнар да инде. Шаян телле егет шыпырт кына Альбираны күзләп йөргән. Биш яшькә яшьрәк булгангамы, сеңел кебек аркасыннан кагып киткәләгән. Берьюлы Альбира бик тырышып конспект язып утырганда барыбер сүз каткан. «Язуың да үзең кебек матур икән», – дип мактап ук куйган. Менә шуннан очраша башлаганнар. Өченче курста укыганда кияүгә чыкса, диплом яклаганда 19 яшьлек Альбираның кулында беренче сабые Илсияре була инде. Ике шатлыкны бергә кичерә студент. Илфруз абый аны гомер буе әнкәсе дип йөртсә, Альбира апа Ильясовна дип дәшә.

– Тормышта хәйләкәр чакларыгыз да булдымы? – дип сорыйм Альбира ападан.

– Ирем бик авыр тормышта үскән. 11 яшьтә әтисе үлгән, тагын бер елдан йорт-җирләре янып беткән. Бөтен әйберне саклап, кадерләп тота. Шуңа күрә аны зур төзелешләр башларга кузгату җиңел булмады. Балалар белән бергә үгетли идек. Башта каршы килсә дә, соңыннан бөтен эшне дәртләнеп башкара иде, – ди ул.

Альбира апа үзен гаилә учагын саклаучы кеше дип саный. Тәмләп, җайлап әйткәндә, ирнең күңеленә ачкыч табу авыр түгел, ди. Әлбәттә, сабырлык кирәк. Каенанасы Мәрьям апа белән 20 ел яшәп, аны тәрбияләп, соңгы юлга озаткан. 87 яшьтә вафат булган ул. Аның шәҗәрәләр, нәселе турында сөйләвен әле дә онытмый.

– Илфруз кайчак кырысрак тоелса да, нечкә күңелле. Газетадан гыйбрәтле хәлләр турында укый башласа, мөлдерәп яшьләре ага. Шифаханәгә барса да, күчтәнәчсез кайтмады. Бу йортны салганда, Пермьгә 4 айга агач әзерләргә китте. Шуннан да посылкалар җибәрде. Иремнең игътибарын тоеп яшим, – ди хуҗабикә.

Гаилә башлыгы да төшеп калганнардан түгел. Армиядә десантчы булып хезмәт иткән. Өйләнешкәч, Лаешта авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлаган. Автомеханик булып эшләгән. Спорт белән шөгыльләнгән: бигрәк тә чаңгы, көрәш, футбол төрләрен үз иткән. Бил алышкан, чаңгыда оста шуган. 1965 елда Казанга барып, команда белән Татарстан буенча беренче урын алганнар.

Адав-Толымбай халкы, Альбира апа – медицина, Илфруз абый тимер-томыр ярдәме күрсәтә, дип әйтә торган булган. Кешеләргә кылган игелекләре үзләренә кайта бүген. Дүрт кыз тәрбияләгәннәр. Олы кызлары Илсияр редакциябездә баш хисапчы булып эшли. Бик тыйнак, сабыр булуы белән аерылып тора. Альбира апа белән Илфруз абыйның 11 онык һәм оныкчыгы бар. Кызлар, кияүләр, оныклар җыелганда өйләре шау-гөр килеп тора икән. «Матур гаилә булып яшәр өчен бер-береңне тыңларга, ишетергә, санларга кирәк. Шул чагында аерылышучылар да булмаячак. Менә шул кагыйдә буенча яшибез», – ди Кәмәртдиновлар.

Сәрия МИФТАХОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз өченче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз өченче утырышын 2022 елның 14 июлендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2022 елның 7 июле
№ 1508-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз өченче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ:**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз өченче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 301-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
3. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 310-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
4. «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү турында» 311-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
5. Татарстан Республикасы Әлки районы Сиктерме-Хузангай авылының исемен үзгәртү турында.
6. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.
7. «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны саклау хакында» Федераль законның 10^6 һәм 15^{1-1} статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында.
8. Авыл җирендә һәм шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга өченче бала туганда бер мәртәбә түләүне билгеләү кирәклеге турында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мөрәҗәгате хакында.
9. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетының 2019 елның сентябреннән 2022 елның июленә кадәрге эш чорына хисабы.
10. Педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы затларга картлык буенча иминият пенсиясен вакытыннан алда билгеләү хокукын бирә торган эш стажына исәпләнә торган эш вазыйфалары исемлегенә физик культура буенча инструктор вазыйфасын кертү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Урынбасары Т.А. Голиковага Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең мөрәҗәгате турында.
11. Белем бирүнең мәктәп системаларын модернизацияләү чараларын гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Мәгърифәт министры С.С. Кравцовка Архангельск өлкә Собраниесе депутатларының мөрәҗәгате турында.
12. «Кулланучылар хокукларын яклау турында» Россия Федерациясе Законының 4 статьясына һәм «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны саклау хакында» Федераль законның 10^6 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 149602-8 номерлы федераль закон проекты хакында (бердәм кушымталар кибете булдыру өлешендә).
13. «Россия Федерациясендә махсус икътисадый зоналар турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 150776-8 номерлы федераль закон проекты турында (концессионерның махсус икътисадый зонада җир кишәрлеге алуга өстенлекле хокукын билгеләү өлешендә).
14. «Россия Федерациясенең Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 150793-8 номерлы федераль закон проекты хакында (капиталь ремонт программасын гамәлгә ашырганда күпфатирлы йортны техник тикшерү өлешендә).
15. «Юл хәрәкәте иминлеге турында» Федераль законның 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 127171-8 номерлы федераль закон проекты турында (Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы гражданнары тарафыннан турыдан-туры транспорт чаралары белән идарә итүгә бәйле эшкуарлык һәм хезмәт эшчәнлеге башкарылганда, аларда гамәлдә булган машина йөртү таныклыкларын тану хакында).
16. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 17.3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 127321-8 номерлы федераль закон проекты турында (судьяның яисә суд приставының судлар эшчәнлегенең билгеләнгән тәртибен тәэмин итү буенча күрсәтмәсен үтәмәгән өчен административ җаваплылыкны көчәйтү хакында).
17. «Юл хәрәкәте иминлеге турында» Федераль законның 23 һәм 28 статьяларына һәм «Персональ белешмәләр турында» Федераль законның 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 149503-8 номерлы федераль закон проекты турында (транспорт чараларын йөртүчеләргә чираттан тыш мәҗбүри медицина тикшерүе үткәрү системасын камилләштерү хакында).
18. Хөкүмәт сәгате: «Татарстан Республикасы территориясендә «Экология» илкүләм проектына керүче «Иделне чистарту» федераль проектын гамәлгә ашыру турында».
19. 2022 елның беренче яртыеллыгында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эше турында мәгълүмат.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2022 елның 7 июле
№ 1509-VI ДС

КОТЛЫЙБЫЗ!

Районның социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы башлыгы **Димитриев** Сергей Димитриевич **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

***

Республиканың ягулык-энергетика комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең эксплуатация хезмәте башлыгы **Анисимов** Олег Юрьевич; халык сәламәтлеген саклау эшендәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Россия Федерациясе Хезмәт һәм халыкны социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Медицина-социаль экспертиза баш бюросы» федераль казна учреждениесенең 23 номерлы бюросы җитәкчесе – медицина-социаль экспертиза буенча табибы **Гафуров** Баязит Солтан улы; һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы гомуми бүлеге башлыгы **Казаченко** Татьяна Евгеньевна, «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте генераль директоры референты – документлар белән тәэмин итү бүлеге белгече **Нургатина** Эльвина Хөрмәтулла кызы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга зур өлеш кертүе өчен «Рыбак, Коган һәм партнерлар» Татарстан Республикасы адвокатлар коллегиясе адвокаты **Коган** Александр Евсеевич; музыка сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Ля Примавера Казан камера оркестры» Казан шәһәре муниципаль автоном мәдәният учреждениесе оркестры концертмейстеры урынбасары **Коростякова** Лия Павловна; татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге өчен язучы, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» җәмәгать оешмасы (Иҗат берлеге) әгъзасы **Сверигин** Рифат Хәсән улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

«Авангард» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш агрономы (Татарстан Республикасының Буа районы) **Гыйматдинов** Хәмит Вагыйзь улына, «Ак Барс» агрокомплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш агрономы (Татарстан Республикасының Арча районы) **Мөхәммәдиев** Рөстәм Харис улына, «Апас-Мол» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Апас-Мол агрономия хезмәте баш агрономы (Татарстан Республикасының Апас районы) **Рәхмәтуллин** Рифат Әүхәт улына **«Татарстан Республикасының атказанган агрономы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Урал» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы сыер савучысы (Татарстан Республикасының Кукмара районы) **Тимергалиева** Раиса Ивановнага **«Татарстан Республикасының атказанган терлекчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Игенче» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (Татарстан Республикасының Яңа Чишмә районы) **Вәлиуллин** Раил Надирҗан улына, «Август-Агро» идарәче компаниясе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Галәветдинов** Айдар Фоат улына, «Азык-төлек программасы агросәнәгать компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Нократ» бүлекчәсе идарәчесе **Мөхәммәтҗанов** Рәшит Миннәхмәт улына, «Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 3 номерлы бүлекчәсе бройлер цехы кош караучысы (Татарстан Республикасының Питрәч районы) **Николаева** Федосия Николаевнага **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Прошу считать недействительной печать организации ЖСК «Кировец-9» (ИНН 1656007805) в связи с ее утерей.

Исәнмесез! Аван-и!

ЧУАШ

Бу сүзне Татарстанда әллә ничә төрле телдә, яратып, кадер-хөрмәт хисләренә төреп әйтәләр. Әмма бу төрлелек аңлашуга һич кенә дә киртә түгел. Хәтта, киресенчә, араны якынайтырга, күңелне баетырга, белемне арттырырга, кызыксынуны басарга булыша торган көчле, кодрәтле сүз ул. Без дә, сөйләшсәк тә төрле телләрдә, дип, шушы кадерле сүзне юл фатихасы итеп, Татарстанның үзенчәлекле авылларына сәфәр чыгарга булдык. «Исәнмесез!» дидек тә бу юлы чуаш дусларыбыз янына – Буа районындагы Чуаш Киштәге авылына юл алдык. Безне алар «Аван-и!» дип каршы алдылар.

10 июльдә Әлки районы Сихтермә-Хузангай авылында Уяв республика чуаш мәдәнияте бәйрәме уза. Шул уңайдан Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов котлау мөрәҗәгате юллады.

«Сезне чуаш халкының кунакчыл Әлки җирендә уздырыла торган җыр-биюле матур бәйрәме – Уяв уңаеннан тәбрик итәм.
Кадерләп саклап, аның буыннан-буынга тапшырыла килгән традицияләре безне гаять бай һәм кызыклы, бик борынгы, үзенчәлекле чуаш мәдәнияте белән таныштыра. Бу – табигатькә, тереклекне яраткан Илаһка, ата-бабалар рухына, игенченең һәм терлекченең игелекле хезмәтенә ихлас мәдхия. Уяв йөрәкләргә җылы өсти, кәефне күтәрә, якты киләчәккә ышаныч һәм өмет уята, үзара җан аваздашлыгы тоеп, гамьле, мәгънәле яшәүгә омтылу хисе тудыра.
Булдыклы, уңган, ачык йөзле, һәркемгә дустанә мөгамәлә күрсәтүче, туган теленә, гореф-гадәтләренә сакчыл мөнәсәбәтле чуашлар, республикабызның үсешенә зур өлеш кертеп, күпмилләтле мәдәниятебезне тагын да бизәп һәм баетып, татарстанлыларның тату гаиләсендә лаеклы урын тота. Аларның йола-бәйрәмнәрендәге үзенчәлекләр, туган җирне ярату, Ватанга тугрылык, башка халыкларга карата хөрмәт чагылыш тапкан кабатланмас җыр-көй иҗаты – уртак мактанычыбыз һәм болар барысы да – дәүләт, муниципаль хакимият органнары, киң җәмәгатьчелекнең игътибары үзәгендә», – диелә анда.
«Татарстанда чуаш мәдәниятен үстерүгә өлеш керткән һәркемгә һәм, беренче нәүбәттә, Чуаш милли-мәдәни мохтарияте әгъзаларына нәтиҗәле эшләре өчен рәхмәт сүзләремне җиткерәм. Тугандаш республикалар – Татарстан һәм Чувашия арасында тыгыз, үзара файдалы элемтәләр бу юнәлештә алгарышыбызга бәрәкәтле этәргеч бирә. Уявның мәйданы ел саен киңәя, анда катнашучылар һәм кунаклар санының арта баруы, аның бөтен Россия күләмендә уздырылуы – күркәм күренеш. Чуаш халык җырлары, мавыктыргыч бәйгеләр, уеннар киләчәктә дә тынмасын, күңелләргә яшәү дәрте өстәсен!
Бу ямьле бәйрәмдә катнашкан һәркемгә рухи күтәренкелек, яхшы кәеф, нык сәламәтлек, тынычлык һәм иминлек, хезмәттә һәм иҗатта яңа уңышлар телим», – дип тәбрикли Рөстәм Миңнеханов.

ШӨГЫЛЬЛЕ АВЫЛ

Буа

Ипи-тоз, үзләре генә белгән рецепт буенча әзерләнгән сыра, чуаш җырлары (башкача мөмкин дә түгел!) белән Чуаш Киштәге авылында каршы алалар. Сый-хөрмәттән авыз итәсе – шул рәвешле бу милләткә ихтирам билгесе күрсәтәсе!

Биредәгеләр кул эшләренә хирыс. Авыл башлыгы Иван Павлов та шулай ди. Чигү, милли киемнәр тегү, бәйләүне, курчаклар, агачка чукып ясауны үз итәләр. Моннан тыш замана шөгыльләрен дә өйрәнәләр. Үз кулибиннары да бар. «Бер тимер кисәге дә тик тормый бездә. Теләсә кайсы хуҗалыкка кереп карасагыз, һәркайсы нәрсә белән дә булса шаккатырачак. Кул эшләрен дә, башка һөнәрләрне дә беләләр. Авылда үзлектән ясалган тракторлар саны гына да 20дән артыктыр. Әле аларны да сезгә күрсәтербез дигән идек тә, эш вакыты бит, барысын да ничек бер урынга җыясың?» – ди Иван Павлов.

Авыл тарихына килгәндә, Чуаш Киштәгенә 1670–1680 нче елларда нигез салынган. Салада, нигездә, чуашлар гына яши. 171 хуҗалыкта якынча 300ләп кеше гомер кичерә.

– Рәхәт яшәү өчен барлык шартлар да бар бездә! Мәктәп – капиталь ремонттан соң, яңа клуб, яңа балалар бакчасы бар, авыл советы бинасы төзекләндерелде. Әле авылда яшьләр бар. Әмма башка җирләрдәге кебек үк кимүгә таба бара. Тик киләчәктә үзгәреш булыр дип уйлыйм. Авылларда шартлар елдан-ел яхшыра бит, – ди башлык.

Кечкенә авылларның өмете-бәхете – эшенә бирелгән энтузиастлар кулында. Моңа беренче генә инанмыйбыз инде. Чуаш Киштәгендә исә ирле-хатынлы Петровлар бу. Бер генә бәйрәм дә алардан башка узмый. Үзләре дә: «Мәдәният йортында яшибез инде без!» – диләр.

Тамара белән Федор Петровлар Алабугада укыганда таныша. Хәзер өйдә дә, эштә дә гел бергә. Музыка, мәдәният – аларның юлдашлары. Федор абзый авылдагы мәдәният учагын тергезеп кенә калучы түгел, әлегәчә ялкынын өстәп торучы да. Балаларны, авыл халкын уен коралларында уйнарга өйрәтә. Сәләтле балаларны ансамбльгә туплый. Әле биергә дә өйрәтәләр. Уен коралларының да ниндиләре генә юк! Балалар гармунын да, баянын да, балалайканы да, барабанны да яхшы белә.

– Балалар үсә тора, шәһәргә китә тора. Ел саен яңаларын туплыйбыз. Өйрәнсеннәр, белсеннәр, дибез. Клубыбыз да уңайлы, шартлары бар бит. Минемчә, шөгыле булган балаларның бозыклыкка, ямьсез гамәлләргә вакыты калмый, – ди Федор абзый. Шунысын да әйтергә кирәк: музыкага мәхәббәте уянган балаларның күпчелеге мәдәният һәм сәнгать училищеларында, институтларында укый икән.

– Безнең авылга эш сәфәре белән килгән Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та бу балаларны күреп сокланды. Әле клубыбыз да начар иде, ремонтка чиратта гына тора идек. «Сезнең кебекләргә акча табасы!» – диде Президентыбыз, шулай клублы да булып куйдык, – дип сөйли әңгәмәдәшебез.

Бу кешеләрнең өйләрендә дә җыр-моң тынмый, диләр. Федор абзый баянда уйнаса, Тамара апа җырлый.

– Чуаш халкының, башкаларныкы кебек үк, үз музыкасы, үз көйләре бар. Күп кенә төбәкләрдә яшәүчеләр җырларны туган телдә тыңлау мөмкинлегеннән мәхрүм. Без чуашлар яшәгән районнарга барабыз, аларны куандырабыз, – ди Федор Петров.

Инде үзләре дә егет белән кыз яшендә түгел. Шулай да күңелләре белән яшьләр. Әле сәламәтлек булганда, тәрбия маяклары булып, авылны яшьнәтеп торырга исәпләре. Шулай булсын гына.

Сүзлек

- ✓Исәнмесез! – **Аван-и!**
- ✓Сау булыгыз! – **Тепре тел пуличчен!**
- ✓Рәхим итегез! – **Ырă сунса кĕтетпĕр!**
- ✓Ашыгыз тәмле булсын – **Апат тутлă пултă**
- ✓Бәхетле булыгыз – **Телейлĕ пулăр**
- ✓Кунакка килегез – **Хăнана килĕр**
- ✓Авыл – **Ял**
- ✓Милләт – **Нацилĕх**
- ✓Рәхмәт – **Тавтапуç**
- ✓Гаилә – **Пер йыш**
- ✓Татулык – **Тĕнче (мир), килĕшӳ (согласие)**
- ✓Дуслык – **Туслах**
- ✓Мәхәббәт – **Юрату**

ОНЫТМЫЙСЫ ИДЕ!

Теле барның иле бар. Әнә шуңа да һәр милләтне тел проблемасы борчый. Киләчәктә балалар туган телдә сөйләшсен өчен нәрсәләр эшләргә? Чуаш Киштәге авылында да бу сорауга җавап эзләдек.

Биредә мәктәптә дә, балалар бакчасында да чуаш теле укытыла. Сүз уңаеннан, белем йортына 45 бала йөри, балалар бакчасында 10 бала тәрбияләнә. Авылда милли бәйрәмнәр булып торганда, шуларны күреп үскән бала-чагасы барда әле киләчәккә өмет бар, дип ышаналар.

Тик читкә киткәч, кызыгы югаламы, кирәксенми башлыйлармы – тел дә, мәдәният тә онытыла. Сәбәпләре күптер дә бит… Авыл башлыгы белән шул хакта фәлсәфә корабыз.

– Чуаш теле 1 нче сыйныфтан башлап 11 нче сыйныфка кадәр укытыла. Дәреслек-әсбапларга кытлык юк, җитәрлек алар. Иң мөһиме – туган телне укыта алырдай бик яхшы белгечебез бар. Ольга Бахтинова – бик милли җанлы кеше. Югары белемле белгеч, җанын биреп укыта. Белем биреп кенә калмый, милли юнәлештә тәрбия белән дә шөгыльләнә, фольклор туплый, кызыксына һәм кызыксындыра. Аның укучылары да даими рәвештә төрле конкурс, фән олимпиадаларында җиңеп тора. Әле менә быел да бер кызыбыз чуаш теленнән олимпиада җиңүчесе булып танылды, – дип сөйли Иван Павлов. – Балалар бакчасында да туган тел үги түгел. Тәрбия урыс һәм чуаш телләрендә бара. Үз телең өйдә генә кирәк, өйдән чыккач, нәрсәгә ул, дип уйлаучы азчылык бар инде ул. Өй шартларында да балалары белән урыс телендә сөйләшүчеләр… аз, әмма бар. Мин исә андый фикерне бер дә хупламыйм. Башка телне өйрәнү берни түгел, аңа һәрвакытта да өлгереп була. Туган телне өйдә булса да кулланасы бит инде. Онытмыйсы!

Иван Павлов милли үзаңны күтәрү өчен менә ни эшләргә кирәк ди (һәм салада шулай эшлиләр дә):

– Булган байлыгыбыз – телебезне һәм мәдәниятне мөмкин кадәр күбрәк күрсәтергә кирәк. Күрсәтеп кенә сеңдереп була. Чаралар, концертлар, спектакльләр, дисеңме. Әлбәттә, бу җәһәттән авыл клубында шактый эш алып барыла. Үзегез үк безнең Петровларны күрдегез бит. Яшьләребез үз көче белән чуаш телендә спектакль дә куя, концертлар да булгалый. Мөмкинлегебездән чыгып, артистларны Ульяновск, Чуашиядән чакырып торабыз. Менә шундый чаралар булып торганда, аларга яшьтән үк балалар йөреп торганда, әле киләчәккә өмет бар. Күргәннәрнең эзе калачак ул.

Иң мөһиме – мәгариф тармагында туган телләрне укытуга урын бирелә. Бу да булмаса, менә куркыныч булыр иде, ди әңгәмәдәшебез. «Ата-ана, өлкән буын вәкилләре буларак, балаларга милләтебезнең бай мирасын тапшыру бурычын тоябыз. Алар да шул хакта уйласын иде. Мәктәпләрдә туган телләре укытылмаган авыллар да бар бит! Менә бу зур минус. Туган телдә белем бирү булмаса – трагедия инде ул. Без әле, Ходай кушса, якын киләчәктә мондый бәла белән очрашмабыз», – дип ышана Иван Павлов.

Тәмле булсын!

nashural.ru

Шартан

Бу – чуашларның иң танылган ит ризыгы. Элек тә, хәзер дә яратып ясала һәм ашала торган сый. Озак әзерләнә торган ризык. Үзенә күрә колбасаны да хәтерләтә. Әмма күпкә тәмлерәк, хуш ислерәк була дип ышандыралар чуашлар.

Авылның хөрмәтле кешесе Вера Леонтьевна безгә әлеге ит сыен ничек дөрес әзерләргә кирәклеген аңлатты:

– Бәрән суйгач, аның итен сөякләрдән аерасы. Бәрәннең ашказаны, ите кирәк. Түбәндә тоз-борыч, төрле тәмләткечләр кулланырга була. Бәрәннең ашказанын юып, эчен тышка әйләндереп, кабат юасы, чайкыйсы, чистартасы. Итне зур булмаган кисәкләргә турап, тозлап-борычлап, яхшылап болгатасы. Шушы итне ашказанына тыгыз иттереп тутырасы, җеп белән нык итеп тегәсе. Бер тәүлеккә мичкә тыгасы. Ризык бик туклыклы, кирәк кадәр тозлы да. Итне үзен генә түгел, маен да тутырырга кирәк, алай ризык тәмлерәк тә чыгачак.

Сәхифәне Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде. Фото – Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6640 данә
Гомуми тираж – 16052 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 297

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+